ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 28 гыйнвары** **Чистай шәһәре** **№ 60**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитеты карарларының
үз көчен югалтуын тану турында

Чистай шәһәр прокуратурасының муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру функцияләрен үтәүнең административ регламентына 2022 елның 25 гыйнварындагы 02-08-02-2022 номерлы протестын карап, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 5 апрелендәге 168 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә бүлеге тарафыннан Чистай муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алкогольле продукцияне ваклап сату өлкәсендәге законнарның үтәлешен тикшерү буенча административ регламентын;
- Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә бүлеге тарафыннан Чистай муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алкогольле продукцияне ваклап сату өлкәсендәге законнарның үтәлешен тикшерүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 5 апрелендәге 168 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 7 августындагы 407 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов